КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 29 ноябрь г.Казань № 1532

2024 елга гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2024 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан гражданнар акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының административ үзәкләре булган торак пунктлардан тыш, Татарстан Республикасы авыл, шәһәр җирлекләре составына керүе торак пунктлар өчен бирелә дип билгеләргә.

2. Карарга теркәлгән 2024 елда гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертларны бүлү методикасын (алга таба - Методика) расларга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнар акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау хакында» 2013 ел, 22 ноябрь, 909 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 14 гыйнвар, 3 нче; 2015 ел, 12 февраль, 85 нче; 2016 ел, 3 октябрь, 706 нчы; 2018 ел, 9 ноябрь, 984 нче, 2021 ел, 19 ноябрь, 1106 нчы, 2022 ел, 23 декабрь, 1397 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып)

расланган Гражданнар акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта:

унөченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«торак пункт территориясен төзекләндерү;»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү».

4. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законы рәсми басылып чыккан көннән алып 10 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджетыннан гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертларның норматив күләмен әлеге Методика нигезендә исәпләп чыгарырга һәм аны Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнарына җибәрергә.

5. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

2024 елда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнар акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау хакында» 2013 ел, 22 ноябрь, 909 нчы карары белән расланган Гражданнар акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе әлеге карарның 1 һәм 2 пунктлары нигезләмәләрен исәпкә алып кулланыла;

әлеге карарның 3 пункты 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 29 ноябрь, 1532 нче карары белән расланды

2024 елда гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертларны бүлү методикасы

Татарстан Республикасының i муниципаль районы өчен башка бюджетара трансфертлар күләме ($S_i$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$S_i = \sum_{j=1}^{n} S_j,$$

монда:

n – заявкага кертелгән, 2023 елның II – IV кварталларында һәм 2024 елның I кварталында бюджетларына 2023 елга кадәрге елда җирле референдумнарда (гражданнар җыеннарында) гражданнарга үзара салым кертү турында кабул ителгән карарлар нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә акча кергән, Татарстан Республикасы i муниципаль районы составына керә торган Татарстан Республикасы авыл һәм шәһәр җирлекләре саны;

$S_j$ - Татарстан Республикасының i муниципаль районы составына керүче Татарстан Республикасы j авыл, шәһәр җирлеге бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләме. Аның зурлыгы түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$S_j = K_c \times ФСc_j,$$
$$әгәр\ S_j > МТп_j,\ то\ S_j = МТп_j,$$

монда:

$K_c$ – гражданнарның үзсалым акчасын җәлеп итеп, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен Татарстан Республикасының j авыл, шәһәр җирлеге бюджетына кергән гражданнарның үзсалым акчасының 1 сумына бирелә торган, түбәндәге сумнарга тигез итеп алынган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы күләме:

4 сум - Татарстан Республикасы авыл, шәһәр җирлекләре өчен (Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегеннән тыш);

3 сум - Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге өчен;

$ФСc_j$ – 2023 елның II - IV кварталларында һәм 2024 елның I кварталында 2023 елда җирле референдумда (гражданнар җыенында) кабул ителгән гражданнарга үзара салым кертү турындагы карар нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл

итүгә Татарстан Республикасы j авыл, шәһәр җирлеге бюджетына кергән гражданнарның үзара салым акчалары күләме, сум;

$МТп_j$ – Татарстан Республикасы j авыл, шәһәр җирлеге өчен үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы авыл, шәһәр җирлеге бюджетына башка бюджетара трансфертларның норматив күләме, ул түбәндәгечә исәпләнә:

Татарстан Республикасы муниципаль районнарының административ үзәкләре булган торак пунктлары булмаган Татарстан Республикасы авыл, шәһәр җирлекләре өчен түбәндәге формула буенча:

$$МТп_j = Ч_j \times МТг \times К_с,$$

Татарстан Республикасы муниципаль районнарының административ үзәкләре булган торак пунктлар составындагы Татарстан Республикасы авыл, шәһәр җирлекләре өчен түбәндәге формула буенча:

$$МТп_j = (Ч_t^i - Ч_k^{it}) \times МТг \times К_с,$$

монда:

$Ч_j$ - Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы мәгълүматлары буенча 2023 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы муниципаль районының административ үзәге булып торучы, составында торак пункт булмаган Татарстан Республикасы j авыл, шәһәр җирлегенең даими халкы саны, кеше;

$Ч_t^i$ - Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы мәгълүматлары буенча 2023 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы i муниципаль районының административ үзәге булып торучы, составында торак пункт булган t авыл, шәһәр җирлегенең даими халкы саны, кеше;

$Ч_k^{it}$ - Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы мәгълүматлары буенча 2023 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы t авыл, шәһәр җирлеге составына керүче k торак пунктының - Татарстан Республикасы i-муниципаль районының административ үзәгенең даими халкы саны, кеше;

МТг - гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы авыл, шәһәр җирлегенең бер кешесенә бирелә торган акчаларның норматив күләме, ул түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$МТг = \frac{ОСсп}{\sum_{j=1}^{m} Ч_j \times К_с + \sum_{t=1}^{n} (Ч_t^i - Ч_k^{it}) \times К_с},$$

монда:

ОСсп - 2024 елга Татарстан Республикасы бюджетында каралган гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле

әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү чараларын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чаралары күләме;

m – Татарстан Республикасы муниципаль районнарының административ үзәкләре булган, составында торак пунктлары булмаган Татарстан Республикасы авыл, шәһәр җирлекләре саны;

n – Татарстан Республикасы муниципаль районнарының административ үзәкләре булган, составында торак пунктлар составындагы Татарстан Республикасы авыл, шәһәр җирлекләре саны.